Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең
Сәрдегән торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 4 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1.«90% күләмендә ташлама билгеләнгән I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләр, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән, торып укучы студентлардан тыш, Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 нче елда үзарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Г.Кутуй урамында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру һәм коймалап алу;
- Г.Кутуй урамнарына 1 янгынга каршы гидрант урнаштыру .

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Салавыч авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarctan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Сибагатуллин